ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

08.09.2023 | Казан шәһәре | № 77

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2016 елның 15 февралендәге 12 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең норматив хокукый актын федераль законнарга яраштыру максатларында

БОЕРЫК БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында» 2016 елның 15 февралендәге 12 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2018 елның 21 февралендәге 19 номерлы, 2022 елның 30 сентябрендәге 111 номерлы, 2023 елның 22 февралендәге 13 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кушымталарны расларга:

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составын.»;

б) Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәдә:

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Комиссия составына Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Инспекциядә дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче комиссия әгъзалары арасыннан Инспекция җитәкчесе тарафыннан билгеләнгән Комиссия әгъзалары, Комиссия секретаре һәм әгъзалары керә. Комиссиянең барлык әгъзалары карарлар кабул иткәндә тигез хокукларга ия. Комиссия рәисе булмый торганда аның вазыйфаларын Комиссия рәисе урынбасары башкара.»;

2.2 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Инспекция җитәкчесенең беренче урынбасары (комиссия рәисе), дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге җитәкчесе, коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе (комиссия секретаре), Хокук эше һәм өлешле төзелешне контрольдә тоту идарәсе юридик бүлегенең, Инспекциянең башка структур бүлекчәләренең Инспекция башлыгы билгели торган дәүләт хезмәткәрләре;»;

3.2 пунктта:

беренче абзацта «атасының исеме» сүзләреннән соң «(соңгысы – булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегендә карала, аны карау нәтиҗәләре буенча «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12 статьясы таләпләрен исәпкә алып, мөрәҗәгатьнең асылы буенча мотивлаштырылган бәяләмә әзерләнә.»;

3.23 пунктта:

«а» пунктчасында «атасының исеме» сүзләреннән соң «(соңгысы – булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

«б» пунктчасында «атасының исеме» сүзләреннән соң «(соңгысы – булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

«д» пунктчасында «атасының исеме» сүзләреннән соң «(соңгысы – булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

в) Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составын өстәргә (кушымтада бирелә).

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.Ф. Сафиуллин

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2016 елның 15 февралендәге 12 номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2023 елның 8 сентябрендәге 77 номерлы боерыгы редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Сафиуллин<br>Илфарт Фәтхрислам улы | Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе җитәкчесенең беренче урынбасары, Комиссия рәисе |
| Нигъмәтуллин<br>Эдуард Валерьевич | Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе җитәкчесе урынбасары, Комиссия рәисе урынбасары |
| Игнатьева<br>Алсу Җәүдәт кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе, Комиссия секретаре |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Булатова<br>Лилия Таһир кызы | Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Хокук эше һәм өлешле төзелешне контрольдә тоту идарәсенең юридик бүлеге җитәкчесе |

| | |
|---|---|
| Волкова Наталья Васильевна | Казан (Идел буе) федераль университетының Идарә, икътисад һәм финанслар институтының дәүләт һәм муниципаль идарә кафедрасы доценты (килешү буенча) |
| Габсәләмова Наталья Алексеевна | Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге җитәкчесе |
| Королев Борис Владимирович | «СТРАТЕГ» КРИЗИСКА КАРШЫ ПРОЦЕДУРАЛАР ҮЗӘГЕ» ФОНДЫның идарә рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе каршында Иҗтимагый совет рәисе (килешү буенча) |
| Мирсәяпов Илизәр Тәлгат улы | Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының (КДАТУ) нигезләр һәм фундаментлар, корылмалар һәм инженерлык геологиясе кафедрасы мөдире, техник фәннәр докторы, профессор, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе каршындагы Иҗтимагый совет әгъзасы (килешү буенча) |
| Панкратов Алексей Юрьевич | Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең оештыру бүлеге мөдире (килешү буенча) |
| Раимов Шамил Надир улы | Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Хокук эше һәм өлешле төзелешне контрольдә тоту идарәсе җитәкчесе |